**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2023 елның 2 мае 1469 номер

# КАРАР

## Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Нармонка авыл җирлеге, Татар Кабаны авылы, Солнечная урамы, 50 адресы буенча урнашкан 16:24:220301:143 кадастр номерлы җир кишәрлеге территориясен чикләү проектын әзерләү турында

Территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьялары нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Нармонка авыл җирлеге, Татар Кабаны авылы, Солнечная урамы, 50 адресы буенча урнашкан 16:24:220301:143 кадастр номерлы җир кишәрлеге территориясен чикләү проектын әзерләү турында.

2. Проектның эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 43 маддәсенә ярашлы рәвештә билгеләргә.

3. Ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрүне исәпкә алып, проектны әзерләү вакытын 2023 елның 27 октябренә кадәр билгеләргә.

4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң ун дүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына территорияне чикләү проектының тәртибе, вакыты һәм эчтәлеге турында тәкъдим-фикерләр җибәрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан

Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А.П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**